РАСЛЫЙМ:
ТР Мөфтиенең беренче урынбасары
Р.Х.Вәлиуллин

**«Динем – Ислам, милләтем – татар» журналистлар эшләре бәйгесен уздыру турында Нигезләмә**

**Конкурсны оештыручы:**

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (алга таба ТР МДН)

**1. Конкурсны үткәрүнең максатлары һәм бурычлары:**
1.1. Максаты – массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан җәмгыятьнең игътибарын татар телен саклау, үстерү һәм өйрәнү мәсьәләләренә, шулай ук милли үзенчәлекләрне саклауда Исламның роленә юнәлтү; татар милләте вәкилләрендә милли үзаң тәрбияләү, аларны туган телне һәм Ислам кыйммәтләрен өйрәнүгә өндәү.

1.2. Милли үзаңны тәрбияләү һәм татар телен саклау мәсьәләләрендә Исламның хәлиткеч ролен яктырткан, татар милләте вәкилләрен туган телне һәм Исламны өйрәнүгә чакырган иң яхшы журналистик материалларны билгеләү; әлеге тематика буенча эшләгән журналистларның һөнәри дәрәҗәсен һәм мәгълүмати материаллар сыйфатын күтәрү.

**2. Конкурсны үткәрү тәртибе:**
2.1. Конкурс турында хәбәр һәм Конкурс турында Нигезләмә конкурсны оештыручының рәсми сайтында (dumrt.ru) игълан ителә.
2.2. Конкурста түбәндәге төп номинацияләргә туры килгән материаллар катнаша ала:
- «Иң яхшы телевизион материал»
- «Иң яхшы радиорепортаж»
- «Басма чараларда иң яхшы язма»
- «Иң яхшы интернет-язма»

2.3. Конкурста катнашучылар: федераль, республика, район, шәһәр электрон, басма, телевидение, радио массакүләм мәгълүмат чараларының журналистлары һәм иҗат берләшмәләре.
2.4. Конкурста катнашу өчен түбәндәге таләпләргә җавап биргән журналист материаллары кабул ителә:
- материаллар 2020 елның 15 февраленнән 30 сентябрьгә кадәр вакыт аралыгында массакүләм мәгълүмат чарасында басылып чыгарга һәм басылып

чыгу турында раслаучы документ белән бергә тапшырылырга тиеш (чыгу вакытын күрсәтә торган скан, эфир белешмәсе);

• материаллар татар яки рус телләрендә эшләнгән булырга тиеш;

• материалларның жанры билгеләнми;

• материалның эчтәлеге, формасы һәм язу стилистикасы конкурс турындагы Нигезләмәнең 3.5 пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килергә тиеш;

• басма материалларның күләме кимендә буш араларны кертеп 3500 билге булырга тиеш;

• аудио һәм видеоматериалларның хронометражы кимендә 3 минут булырга тиеш;

• видео- һәм аудиоматериаллар текстка күчерелгән вариант белән бирелергә тиеш;

• массакүләм мәгълүмат чараларында реклама хокукларында бирелгән материаллар конкурста катнашу өчен кабул ителми;

• конкурста катнашучы эшләр түбәндәге форматларда тапшырыла: басма һәм интернет-язмалар - *.doc, *.docx, видеофайллар - *.avi, аудиофайллар - *.mp3)

2.5. Бер автор конкурста берничә номинациядә катнаша ала.

2.6. Конкурста катнашу өчен конкурс турындагы Нигезләмәнең Кушымтасында күрсәтелгән гариза тапшырыла. Гаризага журналистның эше, видео һәм фотолар, аларның басмага яки эфирга чыгуын раслаучы документлар беркетелә.

Материаллар һәм гариза **«Динем – Ислам, милләтем – татар» конкурсына»** дигән тамга белән 2020 елның 30 сентябреннән дә соңга калмыйча түбәндәге адреска юллана: Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте бүлеге).

Әлеге Нигезләмәдә телгә алынган таләпләргә җавап бирмәгән һәм формага туры килмәгән, тулы булмаган гаризалар, конкурста катнашу өчен кабул ителми.

Элемтә өчен телефон: (843) 237-59-39.
Конкурс эшләрен кабул итүнең соңгы көне – **2020 елның 30 сентябре.**

2.7. Конкурска тәкъдим ителгән материаллар рецензияләнми, түләнми һәм кире кайтарылмый.
2.8. Конкурсны оештыручылар материалны бастыру, тарату һәм тиражлау, шулай ук конкурска килгән материалларны интернет челтәренә кую хокукына ия (авторлыкны күрсәтүче сылтама биреп һәм массакүләм мәгълүмат чарасын күрсәтеп. Гонорар түләнми).

**3. Иҗади эшләрне бәяләү һәм конкурска йомгак ясау**

3.1. Конкурста җиңүчеләр 2020 елның 30 октябреннән дә соңга калмый билгеләнә.

3.2. Конкурсны оештыручы жюри составын төзи.

3.3. Жюри конкурска килгән материалларны әлеге Нигезләмәнең 2.2.нче пунктында күрсәтелгән номинацияләр нигезендә карый.

3.4. Жюри әгъзалары һәрбер материалга әлеге Нигезләмәнең 3.5 нче пунктында күрсәтелгән критерийларны исәпкә алып 1дән алып 10га кадәр балл куя.

3.5. Конкурс эшләренә бәя биргәндә түбәндәгеләр исәпкә алына:

- билгеләнгән темага туры килүе;
- язу стиле һәм материалны бирү осталыгы, аудиториягә йогынтысы;
- материалның мәгълүматларга бай булуы, теманың яктыртылышы;
- мәгълүматны гадел бирү;
- язмалардагы кызыклы геройлар;
- язмаларның саны.

3.6. Һәрбер номинациядә иң яхшы итеп жюри әгъзалары биргән бәяләр буенча иң күп балл җыйган материал танылa. Шундый материалларның авторлары конкурсның җиңүчеләре була.

3.7. Берничә материал иң күп (максималь) балл җыйган очракта материалга жюри әгъзалары тарафыннан югары бәя бирүчеләрнең саны исәпкә алына.

3.8. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр билгеләнә:

- «Иң яхшы телевизион материал»
- «Иң яхшы радиорепортаж»
- «Басма чарада иң яхшы язма»
- «Иң яхшы интернет-язма»

3.9. Һәрбер номинация буенча жюри бер җиңүче һәм ике призер билгели.

3.10. Конкурста җиңүче һәм призер дип танылган материал авторлары дипломнар һәм акчалата бүләкләр белән бүләкләнә:

- 1 урын – 50 000 сум,

- 2 урын – 40 000 сум,

- 3 урын – 30 000 сум;

3.11. Жюри номинацияләр буенча иң яхшы материалларны билгеләмәү хокукына ия.

**4. Конкурсның эшче органнары:** конкурсның жюри составы Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан раслана. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте бүлеге конкурс турында кирәкле мәгълүматны конкурста катнашучыларга җиткерү буенча оештыру функциясе алып бара, конкурска йомгак ясауны үткәрү буенча оештыру чарасы үткәрә.

«Динем – Ислам, милләтем – татар»
журналист эшләре конкурсы
Нигезләмәсенә
Кушымта 1

**«Динем – Ислам, милләтем – татар»**
**журналист эшләре конкурсында**
**катнашу өчен гариза**

| | |
|---|---|
| **Номинация** | |
| **Шәһәр, район, авыл** | |
| **Массакүләм мәгълүмат чарасының исеме** | |
| **Материалның исеме** | |
| **Материалның чыгу датасы** | |
| **Билгеләр (знаклар) саны** *(басма материаллар өчен)* | |
| **Хронометраж** *(видео- һәм аудиоматериал өчен)* | |
| **Автор турында белешмә:** | |
| • паспорт *(туу турында таныклык)* буенча исем-фамилиясе, әтисенең исеме*;*<br>• Тәхәллүсе *(әгәр дә булса)* | |
| **Автор белән элемтәгә керү чаралары** *(почта адресы, телефоны, e-mail)* | |
| **Массакүләм мәгълүмат чарасы турында белешмә:** | |
| **Адрес** *(индекс белән),* **редакциянең телефон номеры** *(шәһәр коды белән)* | |
| **Гаризага кушымта**<br>• **.doc, *.docx форматында язманың тексты*<br>• **.pdf форматында басылып чыккан материал*<br>• **.avi форматында видеофайл (20 Гб зур булмаган)/*<br>• **.mp3 форматында аудиофайл* | |